МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.07.2017 № 477

г.Казань

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 8 августында теркәлде, № 4061

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к  б и р ә м:

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелүнең кушымтада бирелгән тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр в.б. М.Р.Гафаров

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 20.07.2017
№ 477 боерыгы белән
расланды

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган
оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында
түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына
керүгә рөхсәт бирелү тәртибе

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе (алга таба – Тәртип) "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү процедурасын регламентлый.

Бу тәртип Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында алар өчен эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның

идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан язмача, шушы Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән формада төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көненнән дә соңга калмыйча Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алганнан соңгы ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан карар кабул ителгән көннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Гаризаның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге мөһере белән таныкланган, министр резолюциясе куелган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Гаризаның Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының резолюциясе куелган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

___________________________________________

(Ф.И.А.)

___________________________________________

(Ф.И.А., били торган вазыйфа һәм структур

___________________________________________

бүлекчә, яшәгән урын адресы,

___________________________________________

телефон номеры)

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында

ГАРИЗА

Миңа (кирәклесенең астына сызарга)_______________________________________

(иҗтимагый оешманың,

___________________________________________________________________________

торак, торак-төзелеш, гараж кооперативының, яшелчәчелек, бакчачылык,

___________________________________________________________________белән

дача кулланучылар кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең аталышы)

___________________________________________________________________________

(бер кеше кулындагы башкарма органның яисә идарә коллегиаль органының аталышы)

___________________________________________сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашырга, аның идарә коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм.

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | ________________ | ____________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә
2 нче кушымта

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган
оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында
түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары
составына керүгә рөхсәт бирелү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Үтенеч язуын бирүченең Ф.И.А., вазыйфасы | Үтенеч язуын бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |